МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.05.2020 Казан шәһәре № 249

Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара башка трансфертлар бирү өчен кирәкле документларның формаларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара башка трансфертлар бирү һәм бүлү тәртибен раслау турында» (алга таба – Бюджетара башка трансфертлар бирү тәртибе) 2020 елның 27 апрелендәге 342 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында **боерык бирәм**:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

әлеге Боерыкка 1 нче кушымта нигезендә Бюджетара башка трансферт бирүгә гариза формасын;

әлеге Боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар формасын;

әлеге Боерыкның 3 нче кушымтасы нигезендә индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында килешү (алга таба – килешү) формасын.

2. Территориаль үсеш идарәсе җитәкчесенә (В.В. Самсонова) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Бюджетара башка трансферт бирү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) башкарма комитетларыннан бюджетара башка трансферт бирү өчен гаризаларны кабул итү һәм теркәүне;

гаризаны, тапшырылган документларны һәм аларда булган мәгълүматларны Бюджетара башка трансфертлар бирү тәртибендә билгеләнгән таләпләргә һәм шартларга туры килү-килмәве буенча тикшерүне;

килешүләрнең проектларын әзерләүне һәм аларны Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башкарма комитетлары белән төзүне;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башкарма комитетлары тарафыннан әлеге боерык таләпләре һәм Бюджетара башка трансфертлар бирү тәртибе нигезендә тапшырылган хисаплылыкны җыюны һәм тикшерүне.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Н.В.Кондратовка йөкләргә.

4. Әлеге Боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

**Министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2020 елның «__»_______
№ _____ боерыгына
1 нче кушымта

Форма

Бюджетара башка трансферт бирүгә гариза

___________________________________________________________________________

(Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты атамасы)

«___» ___________ 20___ ел

| № | Муниципаль берәмлек атамасы | Индустриаль (сәнәгать) паркы һәм сәнәгать мәйданчыгы атамасы | Чыгымнарны юнәлдерү | Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслашу максатларында бюджетара башка трансферт күләме | Бюджетара башка трансферт бирү турында күрсәтмә номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| 4 | | | | | |
| 5 | | | | | |
| Муниципаль район (шәһәр округы) буенча җәмгысе | | | | | |

_____________________________________/_____________/__________________________________

(Муниципаль район башкарма комитеты, шәһәр округы җитәкчесе вазыйфасының атамасы) (имза) (фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)

«___» _________ 20 __ ел

Теркәлә торган документлар исемлеге:

*1) индустриаль (сәнәгать) паркының һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгының гамәлгә кую документлары күчермәләре;*

*2) индустриаль (сәнәгать) паркы һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы территориясендә җитештерү эшчәнлеген алып баручы кимендә ике теркәлгән резидент булуын раслаучы документлар күчермәләре;*

*3) индустриаль (сәнәгать) паркы һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы территориясендә кимендә 20*

*эш урыны булуын раслый торган документлар күчермәләре;*

*4) индустриаль (сәнәгать) паркын һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгын карап тотуга финанс ихтыяҗы исәпләмәсе һәм аны нигезләү.*

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2020 елның «__»_______
№ _____ боерыгына
2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү яисә бирүдән баш тарту турында 2020 елның «_____» ________________ № ___ карар

| № | Муниципаль берәмлек атамасы | Индустриаль (сәнәгать) паркы һәм сәнәгать мәйданчыгы атамасы | Чыгымнарны юнәлдерү | Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм (яки) сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслашу максатларында бюджетара башка трансферт күләме | Бюджетара башка трансферт бирү яки Бюджетара башка трансферт бирүдән баш тарту нигезе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| Муниципаль район (шәһәр округы) буенча җәмгысе | | | | | |

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары __________/____________________
*(имза, тулы имза)*

Территориаль үсеш идарәсе җитәкчесе __________/____________________
*(имза, тулы имза)*

Инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе __________/____________________
*(имза, тулы имза)*

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2020 елның «__»_______
№ _____ боерыгына
3 нче кушымта

Форма

Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында килешү

Казан шәһәре
«___» ______________20___ ел № ______

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак муниципаль берәмлек бюджетына бюджетара башка трансферт бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, алга таба «Министрлык» дип атала, ____________________________________________
_____________________________________________________________ йөзендә,
(Министрлык җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның вазыйфа атамасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________________ нигезендә эш итә,
(хакимият органы турында нигезләмә, ышаныч кәгазе, боерык яки башка документ)
бер яктан һәм _____________________________________________________,
(муниципаль район, шәһәр округы Башкарма комитеты атамасы)
алга таба «Трансферт алучы» дип атала, _________________________________
_____________________________________________________________ йөзендә,
(муниципаль район, шәһәр округы Башкарма комитеты җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның вазыйфа атамасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
_______________________________________________________ нигезендә эш итә,
(устав, ышаныч кәгазе яки башка документ)
икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, ____ елның «__» _________ ____ номерлы
______________________________________________________________________
(тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы яки тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы законы)
Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 27 апрелендәге 342 номерлы карары белән расланган Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен

финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара башка трансфертлар бирү һәм бүлү тәртибе (алга таба – Бюджетара башка трансфертлар бирү тәртибе) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ________________________________ __________ № _________ карары нигезендә әлеге Килешүне төзеде, түбәндәгеләр хакында:

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан 20___ елда ________________________________________________ бюджетына
(муниципаль район, шәһәр округы атамасы)
___________________________________________________________________
(индустриаль (сәнәгать) паркы һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы атамасы)
карап тоту өлешендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча ___________________________________________________________________
(муниципаль район, шәһәр округы атамасы)
Башкарма комитеты вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә, Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнарын классификацияләүнең түбәндәге кодлары буенча: Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче коды _________, бүлек _______, бүлекчә _______, максатчан статья ________, чыгымнар төре _______, «_______________________________________
___________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы дәүләт программасының аталышы)
____________________________» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «______________________________________________________________________»
(ярдәмче программа атамасы)
ярдәмче программасы буенча Бюджетара башка трансферт (алга таба – Бюджетара башка трансферт) бирүдән гыйбарәт,

2. Бюджетара башка трансферт бирүне финанс белән тәэмин итү

2.1. Бюджетара башка трансферт Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Министрлыкка әлеге Килешүнең 1 бүлегендә күрсәтелгән максатка бирелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә, түбәндәге күләмдә:

20___ елда __________ (_______________) сум ___ тиен.
(сумманы хәрефләр белән язарга)

3. Бюджетара башка трансферт бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Бюджетара башка трансферт _________________ № ________ « ________ ______________________________________________________________________»
(Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законының исеме)

Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә (финанс елына һәм 20___- 20___ еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлеге) һәм финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә бирелә.

3.2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Бюджетара башка трансфертны күчерү Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла:

3.2.1. Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә Федераль казначылыкның территориаль органына ачылган шәхси счетларга;

3.2.2. әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән күләмдә бу Килешү төзелгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә бәйле очракларда Бюджетара башка трансфертлар әлеге Килешү нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән контракт (шартнамә) тапшырылган көннән алып биш көн эчендә исәпләнелә.

## 4. Якларның хокуклары һәм бурычлары

Министрлык түбәндәгеләрне үтәү бурычын үз өстенә ала:

4.1.1. әлеге Килешүнең 3 пункты нигезендә әлеге Килешүдә билгеләнгән Бюджетара башка трансферт бирү шартлары Трансферт алучы тарафыннан үтәлгән очракта, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Бюджетара башка трансферт бирүне тәэмин итәргә;

4.1.2. әлеге Килешүнең 3.2 пункты нигезендә күрсәтелгән Трансферт алучы счетына Бюджетара башка трансферт күчерелүен тәэмин итәргә;

4.1.3. Трансферт алучы тарафыннан тапшырыла торган документларны тикшерергә;

4.1.4. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган әлеге Килешүнең 2 нче кушымтасы нигезендә Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткечен билгеләргә;

4.1.5. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган бу Килешүнең 3 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча, әлеге Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә тапшырылган нәтиҗәлелек буенча максатчан күрсәткечкә ирешү турындагы хисап белешмәләре нигезендә әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан билгеләнгән Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткеченә ирешү йөкләмәсен исәпкә алып, Трансферт алучының Бюджетара башка трансферттан файдалануын бәяләргә;

4.1.6. Трансферт алучы тарафыннан Бюджетара башка трансферт бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары һәм Бюджетара башка трансфертлар бирү тәртибендә һәм

әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләр үтәлешен планлы һәм (яки) планнан тыш тикшерүләр уздыру юлы белән тикшереп торырга:

4.1.6.1. Министрлык урнашкан урын буенча түбәндәгеләр нигезендә:

4.1.6.1.1. 4.3.3 пункт нигезендә тапшырылган, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган, әлеге Килешүнең 4 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча Бюджетара башка трансферттан файдалану турында хисаплар;

4.1.6.1.2. Трансферт алучы тарафыннан 4.3.5 пункт нигезендә Министрлык соратуы буенча тапшырылган башка документлар;

4.1.6.2. Трансферт алучының урнашу урыны буенча Трансферт алучының Бюджетара башка трансферттан файдалануына бәйле операцияләрне документаль һәм фактик анализлау юлы белән.

4.1.7. Трансферт алучы тарафыннан Бюджетара башка трансферт бирү кагыйдәләрендә һәм әлеге Килешүдә каралган Бюджетара башка трансферт бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары бозылу факт(лар)ы турында Министрлык тарафыннан билгеләнгән очракта яисә дәүләт финанс контроле органыннан мәгълүмат алынганда, шул исәптән Трансферт алучы тарафыннан бу Килешү нигезендә тапшырылган документларда төгәл булмаган белешмәләр күрсәтелгәндә, Трансферт алучыга Бюджетара башка трансфертны Татарстан Республикасы бюджетына күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм вакытларда кайтарып бирүне тәэмин итү турында таләп җибәрү;

4.1.8. Трансферт алучыга әлеге Килешүне үтәү белән бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмаларны әлеге Килешүнең 4.4.2 пункты нигезендә Трансферт алучыдан мөрәҗәгать алынган көннән алып 15 эш көне эчендә җибәрергә;

4.1.9. Трансферт алучы тарафыннан җибәрелгән, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә дә, тәкъдимнәрне, документларны һәм башка документларны аларны алган көннән соңгы 10 эш көне эчендә карау һәм кабул ителгән карар турында Вәкаләтле органга хәбәр итү;

4.1.10. Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм Бюджетара башка трансфертлар бирү кагыйдәләре нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашыру.

4.2. Министрлык хокуклары:

4.2.1. бу Килешүнең шартларын үзгәртү турында, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә Трансферт алучы тарафыннан җибәрелгән мәгълүматлар һәм тәкъдимнәр нигезендә дә, Бюджетара башка трансферт күләмен киметү, шулай ук әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән файдаланылмаган бюджет йөкләмәләре лимитлары булганда һәм әлеге үзгәрешкә Трансферт алучыдан финанс-икътисадый нигезләүне үз эченә ала торган мәгълүмат тапшырылуы шарты белән, Бюджетара башка трансферт күләмен арттыру турында карар кабул итәргә;

4.2.2. Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә, Бюджетара башка трансфертның 20 ____ елда файдаланылмаган калдык өлешен 20___ елда әлеге Килешүдә күрсәтелгән максатларга юнәлдерүдә ихтыяҗ булуы яисә

юклыгы турында, Трансферт алучыдан күрсәтелгән максатларга Бюджетара башка трансфертның калдык өлешендә ихтыяҗ булуны дәлилли торган түбәндәге документлар алынган көннән соңгы биш эш көненнән соңга калмыйча карар кабул итү;

4.2.3. Тәртиптә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Бюджетара башка трансферт бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары Трансферт алучы тарафыннан саклануга контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны әлеге Килешүнең 4.1.6 пунктына ярашлы рәвештә Трансферт алучыдан соратып алырга;

4.2.4. Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм Бюджетара башка трансферт бирү кагыйдәләре нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашыру.

4.3. Трансферт алучы түбәндәге бурычларны үз өстенә ала:

4.3.1. Бюджетара башка трансфертны әлеге Килешүнең 1.1 пункты нигезендә чыгымнарны финанслашу максатларында юнәлдерү;

4.3.2. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган, әлеге Килешүнең 2 нче кушымтасында билгеләнгән чараны гамәлгә ашыру кысаларында Бюджетара башка трансферт бирүнең нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткечкә ирешү;

4.3.3. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган бу Килешүнең 3 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча, раслаучы документларның күчермәләрен теркәп, Бюджетара башка трансферт бирүнең нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткеч әһәмиятенә ирешү турында хисапны һәм әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган бу Килешүнең 4 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып Бюджетара башка трансферт торган чыгымнар турындагы хисапны, хисап чорына чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслаучы документларның күчермәләрен теркәп, Министрлыкка тапшыру;

4.3.4. Бюджетара башка трансферт чараларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү;

4.3.5. Министрлык таләбе буенча, әлеге таләп алынган көннән башлап биш эш көне эчендә әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә Бюджетара башка трансферт бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары үтәлүенә контрольлек башкару өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны җибәрү.

4.3.6. Әлеге Килешүнең 4.1.7 пункты нигезендә Министрлыктан таләп алынган очракта:

4.3.6.1. әлеге таләптә билгеләнгән вакыт эчендә Бюджетара башка трансферт бирүнең тәртибе, максатлары һәм шартлары бозылу факт(лар)ын бетерү;

4.3.6.2. әлеге таләптә билгеләнгән күләмдә һәм вакыт эчендә Бюджетара башка трансфертны Татарстан Республикасы бюджетына кайтарып бирү.

4.3.7. әлеге Килешү нигезендә Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тәэмин итү;

4.3.8. Бюджетара башка трансферт бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары үтәлүенә тикшерүләр уздырганда Министрлыкка һәм дәүләт (муниципаль) контрольлек органнарына каршы килмәү;

4.3.9. хисап елыннан соң килгән финанс елының 1 гыйнварына кадәр файдаланылмаган Бюджетара башка трансферт акчаларының калган өлешен Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы бюджетына кайтару;

4.3.10. Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм Бюджетара башка трансфертлар бирү кагыйдәләре нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашыру.

4.4. Трансферт алучының хокуклары:

4.4.1. бу Килешүгә үзгәрешләр кертү турында, шул исәптән Бюджетара башка трансферт күләмен үзгәртү зарурлыгы билгеләнгән очракта да, әлеге үзгәрешкә финанс-икътисадый нигезләүне үз эченә ала торган мәгълүматларны теркәп, Министрлыкка тәкъдимнәр җибәрү;

4.4.2. бу Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә аңлатмалар алу максатында Министрлыкка мөрәҗәгать итү;

4.4.3. әлеге Килешү нигезендә алынган Бюджетара башка трансфертның 20___ елда файдаланылмаган өлешен (булган очракта) 20___ елда шушы Килешүдә күрсәтелгән максатларга туры китереп, түләүләрне башкаруга юнәлдерү, әлеге Килешүнең 4.2.2 пункты нигезендә Министрлыкның тиешле карары кабул ителгән очракта;

4.4.4. Россия Федерациясе бюджет законнары һәм Бюджетара башка трансферт бирү кагыйдәләре нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## 5. Якларның җаваплы булуы

5.1. Әлеге Килешү шартларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясе законнарында каралганча җаваплы була.

5.2. Трансферт алучы әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрнең теләсә кайсысын бозган очракта, әлеге Килешүдә каралган документларны һәм хисапларны тапшырмаган яки вакытында тапшырмаган очракта, әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә билгеләнгән Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткечкә ирешмәгән, төгәл булмаган мәгълүматлар тапшырган, Бюджетара башка трансферттан максатчан файдаланмаган очракта, Министрлык, белдерү алынган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта Бюджетара башка трансферт акчаларын кире кайтаруны таләп итеп, әлеге Килешүне вакытыннан алда өзү турында белдерү җибәрү юлы белән, бу Килешүне өзәргә хокуклы.

Әгәр Бюджетара башка трансферт бирелгән елның 31 декабренә муниципаль берәмлек тарафыннан Бюджетара башка трансферттан файдалануның әлеге

Килешүдә каралган нәтиҗәлелек буенча максатчан күрсәткеченә (нәтиҗәләренә) ирешү буенча йөкләмәләр бозылуга юл куелган булса, Бюджетара башка трансферт муниципаль берәмлек бюджетыннан Бюджетара башка трансферт бирелгән елдан соңгы елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына тулысынча кире кайтарылырга тиеш.

5.3. Бюджетара башка трансфертның агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган өлеше агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кереме итеп кире кайтарылырга тиеш.

5.4. Хисап елыннан соңгы елның 1 гыйнварына файдаланылмаган Бюджетара башка трансферт акчаларының калдык өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә күчерелмәсә, әлеге акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Субсидияләр, субвенцияләр һәм максатчан билгеләнеше булган бюджетара башка трансфертлар формасында алынган бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдык өлешләрен Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә түләттерү тәртибен раслау турында» 2013 елның 4 июлендәге 21-53-35 номерлы боерыгында билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә түләттерелергә тиеш.

## 6. Контроль һәм хисаплылык

6.1. Трансферт алучы Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

6.1.1. 20___ елның 15 гыйнварына кадәр әлеге Килешүнең 3 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча бу Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткеченә ирешү турында хисап;

6.1.2. хисап чорыннан соң килгән айның 7 нче көненә кадәр квартал саен, чыгымнарны раслаучы документларның вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан таныкланган күчермәләрен теркәп, әлеге Килешүнең 3 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча бу Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә Бюджетара башка трансферттан файдалану турында хисап;

6.1.3. Бюджетара башка трансферт бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары үтәлүен тикшереп тору өчен Министрлык тарафыннан соратып алына торган документлар һәм мәгълүмат.

6.2. Бюджетара башка трансферт акчаларын максатчан тотуга контрольлек Министрлык тарафыннан әлеге Килешүнең 6.1 пунктында күрсәтелгән хисаплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 7. Килешүнең гамәлдә булу чоры

7.1.Әлеге Килешү Яклар аңа кул куйган вакыттан башлап үз көченә керә һәм 20___ елның 15 гыйнварына кадәр гамәлдә була.

7.2.Әлеге Килешүнең гамәлдә булу вакытын туктату Трансферт алучыны әлеге Килешүнең 4.3.3, 4.3.5, 6.1.1 һәм 6.1.2 пунктлары нигезендә хисаплылык тапшыру йөкләмәләреннән азат итми.

## 8. Башка шартлар

8.1.Килешүгә теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр фәкать алар язма рәвештә төзелгән һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланганнан соң гына гамәлгә кергән була.

8.2. Әлеге Килешүне үтәү барышында барлыкка килергә мөмкин булган барлык бәхәсләр һәм ризасызлыклар Яклар тарафыннан сөйләшүләр алып бару һәм консультацияләр юлы белән хәл ителәчәк.

8.3. Бәхәсләрне сөйләшүләр алып бару һәм консультацияләр юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, бәхәсләр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә судта хәл ителергә тиеш.

8.4. Әлеге Килешү ике төп нөсхәдә төзелде, алар тигез юридик көчкә ия, һәр Як өчен берәр нөсхәдә.

8.5. Трансферт алучы зат Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Бюджетара башка трансферт бирү тәртибе, шулай ук әлеге Килешү шартларын, максатларын үтәүгә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалык бирә.

## 9. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

| | |
|---|---|
| Министрлыкның атамасы<br>Банк реквизитлары:<br>Банк учреждениеләренең атамасы<br>Банк тәңгәллек коды<br>к/с<br>И-х/сч<br>Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында шәхси счеты:<br><br>ИНН/КПП<br>ОГРН<br>ОКТМО | Трансферт алучының атамасы:<br>Юридик адрес:<br>Банк реквизитлары:<br>Банк учреждениеләренең атамасы:<br>Банк тәңгәллек коды<br>к/с<br>И-х/сч<br>Шәхси счет:<br>ИНН/КПП<br>ОГРН<br>ОКТМО |

## 10. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Министрлык: | Трансферт алучы: |
| ______________/______________/<br>(имза) (тулы имза) | ______________/______________/<br>(имза) (тулы имза) |

Индустриаль (сәнәгать) паркларын
һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап
тоту өлешендә кече һәм урта
эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү
буенча җирле үзидарә органнары
вәкаләтләрен башкарганда барлыкка
килә торган чыгым йөкләмәләрен
финанслашу максатларында,
Татарстан Республикасы
бюджетыннан Татарстан
Республикасы муниципаль
берәмлеге бюджетына бюджетара
башка трансферт бирү турында
«______» _____________ № ______
килешүгә 1 нче кушымта

Форма

Расланды
Татарстан Республикасы
икътисад министры урынбасары
_______________ /______________

20 -___ елга
Бюджетара башка трансферт чараларын тоту юнәлешләре турында смета

| № т/с | Бюджетара башка трансфертны тоту юнәлешләре | Барлыгы | шул исәптән: | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Татарстан Республикасы бюджеты | Муниципаль бюджет |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

Министрлык:
__________/________________
*(имза)* *(тулы имза)*

«____» _________ 20__ ел

Трансферт алучы:
__________/______________
*(имза)* *(тулы имза)*

«____» _________ 20__ ел

Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәга
мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һ
урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү буен
җирле үзидарә органнары вәкаләтләр
башкарганда барлыкка килә торган чыгы
йөкләмәләрен финанслашу максатларын
Татарстан Республикасы бюджетын
Татарстан Республикасы муниципаль берәмл
бюджетына бюджетара башка трансферт би
турында «______» ______________ № ____
килешүгә 2 нче кушымта

Форма

Расланды
Татарстан Республикасы
икътисад министры урынбасары
________________ /_______________

Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткече

| Тәртип саны | Чараның аталышы | Максатчан күрсәткеч исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | Күрсәткечнең план билгесе | Күрсәткечкә ирешү планлаштырылган срок |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Аталышы | Коды | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

Министрлык:
___________/________________
*(имза)* *(тулы имза)*

«____» _________ 20__ ел

Трансферт алучы:
___________/_______________
*(имза)* *(тулы имза)*

«____» _________ 20__ ел

Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында «______» _____________ № ______ килешүгә 3 нче кушымта

Форма

Расланды
Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары
________________ /_______________

20___ елның __ _________ карата
Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткечләренә ирешү турында хисап

Трансферт алучының атамасы: ________________________________________________
Ешлылык: еллык

| Тәртип саны | Чараның аталышы | Күрсәткечнең аталышы | Күрсәткечнең план билгесе | Ирешелгән хисап датасына булган торышында күрсәткеч мәгънәсе | Процент планны үтәү | Сәбәп кире кагу |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Хисап тапшырылды:
Трансферт алучы
__________ / __________ / __________/
*(вазыйфа, имза, тулы имза)*

Башкаручы
__________ / __________ / __________
(*вазыйфа, тулысынча, телефон)*

Министрлык:
___________/_________________
*(имза) (тулы имза)*

«____» _________ 20__ ел

Хисап кабул ителде:
Территориаль үсеш идарәсе җитәкчесе
__________/__________________
*(имза, тулы имза)*

Инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе
__________/___________________
*(имза, тулы имза)*

«____» ___________ 20___ел.

Трансферт алучы:
___________/_______________
*(имза) (тулы имза)*

«____» _________ 20__ ел

Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында «______» _____________ № ______ килешүгә 4 нче кушымта

Форма

Расланды
Татарстан Республикасы
икътисад министры урынбасары
________________ /_______________

20 елның «___» ________ карата

Бюджетара башка трансферттан файдалану турында хисап

Трансферт алучының атамасы: ________________________________________________
Ешлыгы: кварталлык
Үлчәү берәмлеге: сум (икенче дистә билгесенә кадәр төгәллек белән)

| Күрсәткечнең аталышы | Суммасы | | Чыгымнарны тотуны раслый торган документларның реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | Хисап чоры | Ел башыннан бирле арта баручы йомгагы белән | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Агымдагы финанс елы башына Бюджетара башка трансфертның калдык өлеше, барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>расланган ихтыяҗ | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарып бирелергә тиешлесе | | | |
| Күчкән Бюджетара башка трансферт акчалары, барлыгы | | | |
| Хисап датасына касса чыгымнары, барлыгы | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар, барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылганы, барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>агымдагы финанс елы башына Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчаларның калган | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| өлеше | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле, торгызылган акчалар | | | |
| алардан:<br>максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган | | | |
| Хисап чоры ахырына Бюджетара башка трансфертның калган өлеше, барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты кире кайтарылырга тиеш | | | |

Хисапка әлеге таблицаның 4 нче графасында санап үтелгән чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслый торган документларның тиешенчә расланган күчермәләре теркәлә.

Хисап тапшырылды:
Трансферт алучы
__________ / __________ / __________
(*вазыйфа, имза, тулы имза*)

Башкаручы
__________ / __________ / __________
(*вазыйфа, тулысынча, телефон*)

Хисап кабул ителде:
Территориаль үсеш идарәсе җитәкчесе
__________/__________________
*(имза, тулы имза)*

Инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе
__________/____________
*(имза, тулы имза)*

Министрлык:
__________/________________
*(имза) (тулы имза)*

«____» _________ 20__ ел

Трансферт алучы:
__________/_______________
*(имза) (тулы имза)*

«____» _________ 20__ ел